**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422635,РТ, Лаишевский район, село Атабаево, ул.Молодежная, д.1
тел: 8-(84378) -4-87-41
факс: 8-(84378) -4-87-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422635, РТ, Лаеш районы, Атабай авылы, Яшьлэрурамы, 1нчейорт
тел: 8-(84378) -4-87-41
факс: 8-(84378) -4-87-41

2020елның 25ноябре 20 номер

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге Атабай торак пункты гражданнары җыенының карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге Атабай торак пункты гражданнары җыены карар кабул итте**:**

1. Лаеш муниципаль районының Атабай торак пункты _ Атабай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда үзара салым чараларын 500 сум күләмендә кертергә, моңа балачактан көндезге формада белем алучы студентлар һәм инвалидлар керми.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә.:

- Атабай авылында (мәктәп, яр буе урамнары) урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту, сатып алу, ташу, вак таш җәю, асфальт җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү;

3. Әлеге карарны Атабай авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Интернет мәгълүмат телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _________________ Л.Р.Хәлилова

Атабай авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе _______________ Л.Р.Хәлилова